Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге составына керүче Югары Уратма торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елның 12 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлегенең Югары Уратма торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге Югары Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертергә.

2. Алган акчаларны торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга (Яшел урамы буенча юлны ремонтлауга) җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Макаровка авыл җирлеге башлыгы А.Н. Кудряшов